СОВЕТ УТЯШКИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Центральная, д.10,
с. Татарское Утяшкино,423186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
ӘДӘМСӘ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Үзәк урамы, 10
Әдәмсә авылы,423186

тел.: (8-84348) 3-47-41, факс: (8-84348) 3-47-65, Ut.Nsm@tatar.ru

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

2023 елның 15 июнендә — № 34-128

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советы 28.11.2012 №19-57 «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләре турында» карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Җир кодексы, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Әдәмсә авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының 28.11.2012 №19-57 карары белән расланган, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә (30.01.2017 №24-50, 27.01.2021 №8-21 карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 30 статьяның 1.1 өлешенең «Җир кишәрлекләреннән һәм капиталь төзелеш объектларыннан рөхсәт ителгән файдалануның төп төрләре» икенче абзацына түбәндәге эчтәлекле пунктчалар өстәргә:

«- индивидуаль торак төзелеше өчен;
- шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен (йорт янындагы җир кишәрлеге);
- яшелчәчелек алып бару өчен;
- коммуналь хезмәт күрсәтү;
- коммуналь хезмәтләр күрсәтү;
- гараж;
- хуҗалык сарае;
- базарлар;
- кибетләр;
склад бүлмәләре.»

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Порталында Яңа Чишмә муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/ бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Әдәмсә авыл җирлеге Советының законлылык, экология, җирдән файдалану, торак-коммуналь хуҗалык һәм территорияне төзекләндерү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Әдәмсә авыл җирлеге башлыгы А.Н. Назмутдинова